РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**КАРАР** **КАРАР**

2023 елның 27 гыйнвары Кукмара ш. № 170

Кукмара муниципаль районы Советының 2018 елның 27 июлендәге 168 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Кукмара шәһәре җирлеге Советы **карар бирде:**

1. Кукмара муниципаль районы Советының 2018 елның 27 июлендәге 168 номерлы карары белән (2022 елның 24 августындагы 139 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 6 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Үткәрү вакытын һәм урынын күрсәтеп, гавами тыңлауларны билгеләү турында мәгълүмат, шулай ук гавами тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты гавами тыңлауларны үткәрү көненә кадәр 7 календарь көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырылырга, шул исәптән Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Бердәм портал) бастырылырга тиеш».

Кукмара муниципаль районы халкына хәбәр итү максатларында гавами тыңлауларны билгеләү турында мәгълүматны һәм муниципаль норматив хокукый

акт проектын Бердәм порталда урнаштыру, җирле үзидарә органының шәхси кабинетын кулланып, бердәм порталның кире элемтә платформасының тиешле бүлегендә (алга таба - органның шәхси кабинеты) әлеге пунктның беренче абзацы белән билгеләнгән срокта Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының вәкаләтле хезмәткәре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Гавами тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлауларга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча үз фикерләрен һәм тәкъдимнәрен шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша җибәрергә хокуклы.

Фикер алышуга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр Кукмара муниципаль районы халкы тарафыннан, «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификациянең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланып авторизация үткәннән соң, Бердәм порталны кулланып кертелә.

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кертү гавами тыңлауларны билгеләү турында мәгълүматны һәм гавами тыңлауларга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проектын бастырып чыгару датасыннан башлана һәм гавами тыңлаулар үткәргән көнгә кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Кукмара муниципаль районы халкы, муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча кисәтүләр һәм тәкъдимнәр керткәндә, шулай ук үзләренең фамилияләре, исеме, атасының исеме (булса), гражданның шәхесен раслаучы төп документның реквизитлары, туган көне һәм яшәү урыны буенча теркәү адресы турында мәгълүмат җибәрә.

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр органның шәхси кабинетына җибәрелә.»;

б) 6 статьяның 1.1 өлешендәге беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре, кабул ителгән карарларның мотивацияләнгән нигезен кертеп, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырыла (халыкка җиткерелә), шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында, «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында гавами тыңлаулар уздырылганнан соң 5 календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштырыла.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Район Башлыгы С. Д. Димитриев